Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә Советы

КАРАРЫ

26 апрель 2024 ел №108

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә Уставының XV бүлеге, 2023 елның 20 ноябрендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 07 августындагы 02-08-02/836 номерлы күрсәтмәсен карап

Түбән Мактама бистә Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2011 елның 6 октябрендәге 55 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә Уставына (Түбән Мактама бистә Советының 2012 елның 04 июлендәге 96 номерлы, 2013 елның 28 августындагы 146 номерлы, 2014 елның 18 декабрендәге 218 номерлы, 2016 елның 12 маендагы 38 номерлы, 2017 елның 12 апрелендәге 71 номерлы, 2018 елның 04 июлендәге 124 номерлы, 2019 елның 14 маендагы 161 номерлы, 2020 елның 14 маендагы 185 номерлы, 2021 елның 28 сентябрендәге 36 номерлы, 2023 елның 19 маендагы 83 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымтага нигезләнеп үзәрешләр кертергә:

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә

3. Әлеге карарны Әлмәт районы, Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе, Некрасов урамы, 18А йорт, 30А йорт, Заводская урамы, 2А йорт, Достоевского урамы, 10 йорт, Х.Атласи урамы, 1А йорт, Советская урамы, 84 йорт һәм Тихоновка авылы, Терешковой урамы, 34А йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, “Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясының 8 өлешенә ярашлы рәвештә үз көченә керә.

5. Карарның 1 пунктының “а” пунктчасы, 4 пунктының “а” пунктчасы 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә башлыгына йөкләргә.

Түбән Мактама шәһәр
тибындагы бистә башлыгы Р.А. Бәдретдинов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә Советының
2024 елның 26 апрелендә
108 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе
Уставына үзгәрешләр кертү

1) 6 статьяның 1 өлешендә:

а) 27 пунктта «җирлек территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

б) 29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

в) түбәндәге эчтәлектәге 40 пункт белән тулыландырырга:

"40) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм мондый зыянны бетерүне торак пункт милкендәге җир участоклары чикләрендә урнашкан территорияләргә карата оештыру.»;

2) 30 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 7.1 өлеше белән тулыландырырга:

«7.1. Җирлек Советы депутаты «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны, чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, булган хәлләр бәйсез тикшерү тарафыннан күрсәтелгән затларга «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә таныла»;

1) 43 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 2.1 өлее белән тулыландырырга:

«2.1. Җирлек башлыгы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны, чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, булган хәлләр бәйсез тикшерү тарафыннан күрсәтелгән затларга «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә таныла»;

б) 5 өлешне төшереп калдырырга;

4) 49 статьяда:

а) 3 пунктның унынчы абзацында «җирлек территориясендә дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны

булдыра, үстерә һәм саклауны тәэмин итә, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге яңа абзац белән тулыландырырга:

«- әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм мондый зыянны бетерүне торак пункт милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата оештыра;»;

в) 1 өлешнең 5 пунктының унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнаша;»;

г) 10 пунктның бишенче абзацында «федераль законнар» сүзләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләре белән алыштырырга

д) 10 пунктны түбәндәге эчтәлектәге яңа абзац белән тулыландырырга:

«-муниципаль хокукый актларны игълан итү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен басма массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яки) челтәр басмасы булдыра.»;

5) 50 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 6.1 өлеше белән тулыландырырга:

«6.1. Җирлекнең башкарма комитеты җитәкчесе «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны, чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, булган хәлләр бәйсез тикшерү тарафыннан күрсәтелгән затларга «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә танылса»;

6) 64.1. статьясында:

а) 1 өлешнең 1 пунктын «, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

б) 1 өлешнең 2 пунктында «белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган мәгълүматны күрсәтүне» сүзләрен «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган белешмәләр бирү, яисә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру" сүзләре белән алыштырырга;

в) 2 өлешне «, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга.

7) 77 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«77 статья. Муниципаль хокукый актларны игълан итү һәм аларның үз көченә керү тәртибе»**

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, нигез салучы булып торган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең рәсми игълан ителүе булып аларның:

1) Тулы текст рәсми рәвештә Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru, Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор)ның ЭЛ ФС77-60244 номерлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык 17.12.2013) яки «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, (Татарстан Республикасы буенча мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр элемтә өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсенең ПИТУ-16-00933 номерлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык 27.12.2012);

2) Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру (https://www.almetevsk.tatarstan.ru).

3) Җирлек территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру: Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе, Некрасов урамы, 18А йорт, 30А йорт, Заводская урамы, 2А йорт, Достоевского урамы, 10 йорт, Х.Атласи урамы, 1А йорт, Советская урамы, 84 йорт һәм Тихоновка авылы, Терешковой урамы, 34А йорт.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталыннан файдалана алуын тәэмин итү өчен җирлек башкарма комитеты бинасында урнашкан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пункты эшли: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе, Некрасов урамы, 18А йорт.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, муниципаль хокукый актлардан яки Федераль закон белән чикләнгән мәгълүматлар булган аерым нигезләмәләрдән тыш, имзаланганнан соң 10 көн эчендә игълан ителә.

5. Җирлек Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексына ярашлы рәвештә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр акт белән башканы билгеләмәсә, имзаланган көннән үз көченә керә.

7. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә тиешле сайтларның домен исемнәре һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы мәгълүматлар күрсәтелгән вакытлы басмалар, челтәр басмалары исемлеге, аларда муниципаль хокукый актлар, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр игълан ителә (рәсми басмадан кала), җирлек башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән бөтен кешегә җиткерелә.».

Түбән Мактама шәһәр тибындагы
бистә башлыгы Р.А. Бәдретдинов